**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 декабрь № 931

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 13 декабрь, 985 нче, 2015 ел, 20 март, 179 нчы, 2015 ел, 15 сентябрь, 677 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктка «тапшырылган вәкаләтләре кысаларында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаның бурычлары» юлының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар формалаштыру, шул исәптән территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә;»;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында:

беренче абзацта «2014 – 2015 еллар» сүзләрен «2014 – 2020 еллар» сүзләренә

алмаштырырга;

өченче абзацта «2014 – 2015 еллар» сүзләрен «2014 – 2020 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 43 029 625,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: |

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты | Җәлеп ителергә планлаштырылган акча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет | дәүләт корпорациясе – коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 6953839,3 | 2203224,4 | 151597,7 | 1377870,6 | 1072210,0 | 2148936,6 |
| 2015 | 8361536,4 | 3336365,9 | 476375,4 | 1270032,2 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2016 | 6518355,1 | 2052328,7 | 91031,5 | 1096232,0 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2017 | 5793614,2 | 2074129,6 | 89987,7 | 350734,0 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2018 | 5117899,9 | 1836637,0 | 2500,0 | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2019 | 5134574,0 | 1853311,1 | 2500,0 | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2020 | 5149806,4 | 1868543,5 | 2500,0 | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| Барысы | 43029625,3 | 15224540,2 | 816492,3 | 4094868,8 | 7509796,0 | 15383928,1 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш»;

«Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының дүртенче абзацында «100» саннарын «186» саннарына алмаштырырга;

Программаның 1 бүлегендәге 1.1 пунктның 1 нче таблицасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максачан программасы турында» 2010 ел, 17 декабрь, 1050 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максачан программасы»ның (алга таба – «Торак» ФМП) «Федераль законнарда билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» ярдәмче программасы кысаларында түбәндәге чаралар тормышка ашырыла: хәрби хезмәттән чыгарылган гражданнарны торак белән тәэмин итү, чернобыльчеларны, мәҗбүри күченеп кайтучыларны, Ерак Төньяк районнарыннан китүчеләрне торак белән тәэмин итү.»;

Программаның 2 бүлегендә:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар

формалаштыру, шул исәптән территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә;»;

егерме өченче абзацта «100» саннарын «186» саннарына алмаштырырга;

2.1 пунктның беренче һәм дүртенче абзацларында «2014 – 2015 еллар» сүзләрен «2014 – 2020 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. «2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаны эшләү өчен нигезләр: «Торак» ФМПның «Россия Федерациясе субъектларының торак төзелешен үстерү программаларын стимуллаштыру» ярдәмче программасы; «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм күрсәтү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон; Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак белән тәэмин итү һәм торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 600 нче Указы.

Ярдәмче программаның төп максаты - территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар формалаштыру.

Ярдәмче программа кысаларында Татарстан Республикасы бюджетына торак төзелешен үстерү программаларын тормышка ашыруга субсидияләр алу буенча чаралар гамәлгә ашырылачак, алар түбәндәгеләргә файдаланыла ала:

экономик классны торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен инженерлык инфраструктурасы белән тәэмин итү максатларына заемчылар тарафыннан Россия кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча процентлар түләүгә чыгымнарны (чыгымнарның өлешен) кайтаруга;

экономик классны торак төзелешен күздә тоткан территорияләрне комплекслы үстерү буенча проектларны тормышка ашыру кысаларында социаль инфраструктура объектларын төзүгә (төзекләндерүгә);

экономик классны азкатлы һәм күпфатирлы торак массакүләм төзелгән микрорайоннарда автомобиль юлларын төзүгә (төзекләндерүгә).

Федераль милектәге нәтиҗәсез файдаланылучы җир кишәрлекләрен, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү буенча чаралар кысаларында мондый җир кишәрлекләрен ачыклау буенча эш, әлеге җир кишәрлекләрен киләчәктә файдалану мәсьәләсен эшләү күздә тотыла.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын су белән тәэмин итү һәм җылылык белән тәэмин итү хезмәтләре белән тәэмин ителешен яхшырту» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның максатлары:

халыкны билгеләнгән санитар-эпидемиологик нормаларга туры килә торган чиста эчәргә яраклы су белән тәэмин итү;

су белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгына һәм ресурслары нәтиҗәлелегенә ирешү;

торак-коммуналь комплекс оешмаларының җылылык белән тәэмин итү системаларының эшләү нәтиҗәлелеген күтәрү.

Ярдәмче программаның бурычлары:

халыкның үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм су агызу хезмәтләре белән тәэмин ителешен күтәрү;

заманча технологияләр кертеп, су белән тәэмин итү системаларын үстерү;

суны рациональ файдалану һәм эчәргә яраклы суны югалту күләмнәрен киметүне тәэмин итү;

авыл халкына җылылык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча сыйфатлы коммуналь хезмәтләр күрсәтү;

авыл халкын аварияләрсез, өзлексез җылылык белән тәэмин итү һәм кайнар су белән тәэмин итү чыганаклары белән тәэмин итү.

Ярдәмче программа чаралары түбәндәгеләргә булышачак:

гражданнарның яшәү дәрәҗәсен һәм уңайлылыгын күтәрүгә;

авыл халкының коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен күтәрүгә;

кулланучылар өчен коммуналь хезмәтләрнең һәркем алырлык булуын саклауга;

кулланучыларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын, ышанычлылыгын һәм экологик иминлеген күтәрүгә;

җылылык белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә түләүне киметүгә;

табигый газ куллануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә.»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү фаразы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет, Дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2014 – 2020 елларда Программаны финанслауның фаразлана торган гомуми күләме 43 029 625,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлык акча | Татарстан Республикасы бюджеты | Җәлеп итергә планлаштырылган акча | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | федераль бюджет | Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды | җирле бюджетлар | бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2014 | 6953839,3 | 2203224,4 | 151597,7 | 1377870,6 | 1072210,0 | 2148936,6 |
| 2015 | 8361536,4 | 3336365,9 | 476375,4 | 1270032,2 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2016 | 6518355,1 | 2052328,7 | 91031,5 | 1096232,0 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2017 | 5793614,2 | 2074129,6 | 89987,7 | 350734,0 | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2018 | 5117899,9 | 1836637,0 | 2500,0 | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2019 | 5134574,0 | 1853311,1 | 2500,0 | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| 2020 | 5149806,4 | 1868543,5 | 2500,0 | - | 1072931,0 | 2205831,9 |
| Барлыгы | 43029625,3 | 15224540,2 | 816492,3 | 4094868,8 | 7509796,0 | 15383928,1 |

Программа юнәлешләре буенча финанслау күләмнәре, тиешле бюджетлар мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Барлык чыганаклар исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү һәм Программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының фараз кыйммәте бу Программага теркәлгән кушымтада китерелә.»;

Программага кушымтада:

«Ярдәмче программа исеме: «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» һәм «Яшь гаиләләргә экономик классны торак сатып алуга социаль түләүләр бирү» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Ярдәмче программа исеме: «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Яшь гаиләләргә экономик классны торак сатып алуга социаль түләүләр бирү | Яшьләр эшләре министрлыгы, ҖҮО, экономик классны торак урыннар бирү буенча вәкаләтле оешмалар һәм федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар буенча сайлап алынган банклар | 2014 – 2020 | Хисап елында торак урыннар алган һәм торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләр саны («2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кысаларында), берәмлек | 87 | 67 | 69 | 50 | 45 | 40 | 35 | 30 | 50000,0 ТРБ<br><br>10291,29 ФБ<br><br>79000,0 БТ | 50000,0 ТРБ<br><br>11958,04 ФБ<br><br>79000,0 БТ | 50000,0 ТРБ<br><br>2500,0 ФБ<br><br>79000 БТ | 50000 ТРБ<br><br>2500,0 ФБ<br><br>79000,0 БТ | 50000,0 ТРБ<br><br>2500,0 ФБ<br><br>79000,0 БТ | 50000,0 ТРБ<br><br>2500,0 ФБ<br><br>79000,0 БТ | 50000,0 ТРБ<br><br>2500,0 ФБ<br><br>79000,0 БТ»; |

«Бурыч исеме: торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар формалаштыру, шул исәптән нәтиҗәле файдаланылмый торган федераль җирләрне әйләнешкә кертү һәм территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә», «Ярдәмче программа исеме: «2014 – 2015 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру» һәм «Экономик классны торак төзү өчен социаль һәм инженер инфраструктураны, алып килә торган автоюлларны үстерү» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Бурыч исеме: торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар формалаштыру, шул исәптән территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру өлешендә | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ярдәмче программа исеме: «2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Нәтиҗәле шәһәр төзү сәясәтен үткәрүгә, экономик классны торак төзү өчен шартлар тудыруга стимуллаштыру | ТАҺТКХМ, ҖҮО (килешү буенча), юридик затлар (килешү буенча) | 2014 – 2020 | Торакны гамәлгә кертүнең гомуми күләмендә экономик классны торакны гамәлгә кертү өлеше, % | 16 | 16 | 17 | 17,5 | 18,5 | 19 | 20 | 20 | 0 | 377806,96 ФБ<br><br>161917,269 ТРБ | * | * | * | * | *»; |

«Архитектура, шәһәр төзелеше, граждан һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының гомумпрограмма эшчәнлеге» юлында:

«Торакны кулланылышка тапшыруның гомуми еллык күләмендә экономик

классლы торакны кулланылышка тапшыру өлеше, %» ярдәмче юлын төшереп калдырырга;

«Җитештерү булмаган билгеләнештәге капиталь төзелешнең үрнәк объектын төзүгә рөхсәт алу өчен кирәкле эзлекле гамәлләрнең чик саны, берәмлек» ярдәмче юлында 6 графада «30» саннарын «32» саннарына алмаштырырга;

«Җитештерү булмаган билгеләнештәге капиталь төзелешнең үрнәк объектын төзүгә рөхсәт алу өчен кирәкле эзлекле гамәлләрне үтүнең чик вакыты, көн» ярдәмче юлында:

6 графада «280» саннарын «200» саннарына алмаштырырга;

9 графада «75» саннарын «70» саннарына алмаштырырга;

«Дәүләт программасы буенча барысы, шул исәптән:» һәм «федераль бюджет» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Дәүләт программасы буенча барысы, шул исәптән: | 69953839,3 | 8361536,4 | 6518355,1 | 5793614,2 | 5117899,9 | 5134574,0 | 5149806,4 |
| федераль бюджет | 151597,7 | 476375,4 | 91031,5 | 89987,7 | 2500,0 | 2500,0 | 2500,0»; |

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы бюджеты | 2203224,4 | 3336365,9 | 2052328,7 | 2074129,6 | 1836637,0 | 1853311,1 | 1868543,5»; |

«бюджеттан тыш чыганаклар» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «бюджеттан тыш чыганаклар | 2148936,6 | 2205831,9 | 2205831,9 | 2205831,9 | 2205831,9 | 2205831,9 | 2205831,9»; |

Программага «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын 1 нче кушымтага ярашлы редакциядә бәян итәргә;

Программага «2014 – 2020 елларга территорияләрне комплекслы үзләштерү һәм үстерү проектларын тормышка ашыру» ярдәмче программасын 2 нче кушымтага ярашлы редакциядә бәян итәргә;

Программага «2014 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтен тормышка ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортында «Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җылылык изоляцияләүче материаллар – 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына 73 куб.метр;»;

Ярдәмче программаның 2 бүлегендәге унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзү материаллары сәнәгате продукциясе исемлеген киңәйтү һәм чыгару күләмнәрен арттыру, төзелеш индустриясе продукциясен кертүне киметү һәм чыгару күләмен арттыру, республика базарын конкурентлылыкка сәләтле куллану өстенлекләре булган, үзебез җитештергән төзү материаллары белән тутыру. Бетон һәм тимербетон әйберләр җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына 0,28 куб.метр тәшкил итә. Вак данәле дивар материалларын җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә,

елына 180 данә шартлы кирпеч тәшкил итә. Җылылык изоляцияләүче материаллар җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына 0,73 куб.метр тәшкил итә.»;

Ярдәмче программага кушымтада «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының архитектура, шәһәр төзелеше, граждан һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә гомумпрограмма эшчәнлеге» юлында:

«2015 елның 1 гыйнварына 2020 елга кадәр төзелешне гамәлгә ашыру өчен территорияләрне планлаштыру проектларын раслау планлаштырылган шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләре санында территорияләрне планлаштыру проектлары расланган шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләре өлеше, %» ярдәмче юлының 5 графасында «100» саннарын «86» саннарына алмаштырырга;

«Торакны кулланылышка тапшыруның гомуми еллык күләмендә экономик класслы торакны кулланылышка тапшыру өлеше, %» ярдәмче юлын төшереп калдырырга;

«Җитештерү булмаган билгеләнештәге капиталь төзелешнең үрнәк объектын төзүгә рөхсәт алу өчен кирәкле эзлекле гамәлләрнең чик саны, берәмлек» ярдәмче юлында 5 графада «30» саннарын «32» саннарына алмаштырырга;

«Җитештерү булмаган билгеләнештәге капиталь төзелешнең үрнәк объектын төзүгә рөхсәт алу өчен кирәкле эзлекле гамәлләрне үтүнең чик вакыты, көн» ярдәмче юлында:

5 графада «280» саннарын «200» саннарына алмаштырырга;

8 графада «75» саннарын «70» саннарына алмаштырырга;

«Бетон һәм тимербетон әйберләр җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына куб.метр» ярдәмче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Бетон һәм тимербетон әйберләр җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына куб.метр | 155 | 160 | 165,7 | 165,7 | 165,7 | 172 | 175 | 180»; | | | | | | | | |

«Җылылык изоляцияләүче материаллар җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына куб.метр» ярдәмче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Җылылык изоляцияләүче материаллар җитештерү, 1 яшәүчегә исәпләгәндә, елына куб.метр | 0,32 | 0,73 | 0,73 | 0,73 | 0,73 | 0,73 | 0,73 | 0,73»; | | | | | | | | |

«Татарстан Республикасы халыкның гомуми санында куркынычсызлык таләпләренә җавап бирә торган эчәргә яраклы су белән тәэмин ителгән халык өлеше, %»:

10 графада «96,3» саннарын «95,8» саннарына алмаштырырга;

11 графада «97,0» саннарын «96,0» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков